**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**13.12.2016** **№ 01-02/309**

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрын раслау турында» 2014 елның 04 февралендәге № 01-02/9 номерлы боерыгына үзгәреш кертү турында

«Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Алан авылының гамәлдә булуын юкка чыгару һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, боерам:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрын раслау турында» 2014 елның 04 февралендәге № 01-02/9 номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2014 елның 19 декабрендәге № 01-02/599 нчы, 2015 елның 11 мартындагы № 01-02/160 нчы,

2016 елның 02 мартындагы № 01-02/76 нчы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасында административ-территориаль берәмлекләр һәм торак пунктлар реестрына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

7 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 бүлек. 2016 елда Татарстан Республикасы административ-территориаль корылышына үзгәрешләр исемлеге

| № п/п | Үзгәрешләрнең эчтәлеге | Нигезендә үзгәреш кертелә торган хокукый акт реквизитлары | Нигезендә үзгәреш кертелә торган хокукый актның үз көченә керү датасы | Реестрга үзгәреш керү турында язма кертелгән дата |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Алан авылының гамәлдә булуын юкка чыгару | «Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Алан авылының гамәлдә булуын юкка чыгару һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы | 02.12.2016 | 12.12.2016» |

Министр Л.Ю.Глухова